РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» марта 2021 г. г. Альметьевск № 24

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм түләү күләмнәренең торышы турында» 2015 елның 29 декабрендәге 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 13 ноябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, бюджет акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелеге принцибын үтәүне һәм республика законнары нормаларына туры килүне тәэмин итү максатларында

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм түләү күләмнәренең торышы турында» 2015 елның 29 декабрендәге 24 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2020 елның 23 июнендәге 201 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 6 пунктта түбәндәге эчтәлекле 6.1 пунктча өстәргә:

«6.1. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бүләкләү муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләре булмаганда түләнә. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү өчен мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынганда, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү мондый түләү сорап мөрәҗәгать иткән көннән башкарыла».

Зак. № 2624

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет-финанс мәсьәләләре буенча шәһәр Советының даими комиссиясенә (Мусин Р.Ф.) йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы — Т.Д. Нагуманов